Республика Татарстан
Рыбно-Слободский
муниципальный район
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Юлсубинского сельского поселения
422669, с.Юлсубино.
ул.Татарстана , дом 56 а

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлегенең
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422669, Юлсубино авылы.
Татарстан урамы, 56 а

тел:8(84361)30-223, факс :8(84361)30-223 эл .почта Uls.Rs@tatar.ru

Карар №5

02 апрель 2024

Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 июле 10 нчы номерлы карары белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 05.02.2024 ел №124 карарына, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 11.02.2022 ел №28пи карарына ярашлы рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1. Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 июль 10 нчы номерлы карары белән расланган административ регламентына (08.12.2021 ел №16 карар ред. дә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында карар кабул итү, адресация объектына адресациядән баш тарту яки аның адресын гамәлдән чыгару турында карар кабул итү, шулай ук дәүләт адреслар реестрында адресация объектының адресы турында тиешле мәгълүматларны урнаштыру вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәгечә башкарыла:

а) кәгазь йөрткечтә гариза биргән очракта гариза килгән көннән алып 10 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә;

б) электрон документ рәвешендә гариза биргән очракта гариза килгән көннән алып 5 эш көненнән дә артык булмаган вакытта.»;

1.2) 2.3.2 пунктында «берләштерелергә мөмкин» сүзләрен «берләштерелә» сүзенә алмаштырырга;

1.3) 1.2 пунктның 10 абзацында «Әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән» сүзләрен «гариза белән» сүзләренә алмаштырырга;

2.Карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы,Юлсубино авылы, Татарстан урам, 56 йорт,Ямаш авылы Х.Такташ урамы 3в йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлеге башлыгы                                        Х.Х.Гатиятов